**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**15 ноябрь 2024 ел** **№ 4**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Югары Чыршылы авылында 2025 елда үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Югары Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Югары Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тору (Югары Чыршылы торак пунктында юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча йөртүче эшләре һәм хезмәт күрсәтүләре өчен түләү); (Югары Чыршылы торак пунктында жирлек Юлы эчендә ремонтлау (ташу, вак таш салу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт территориясен чабу (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү): трактор тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу); (Югары Чыршылы торак пунктында агачлар, куаклар кисү (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

3) халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау (балалар мәйданчыгы территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, Югары Чыршылы торак пунктына койма кую хезмәтләре өчен түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Камалетдинов